**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительного комитета Азнакаевского муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**«01» апрель 2020 ел** **№ 98**

Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 13 мартындагы 56 номерлы «Халык алдында чаралар үткәрү урынында территорияне (бинаны) иң чик тутыру нормалары турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Гавами чараларда катнашучы гражданнарның иминлеген, гавами чаралар уздыру өчен файдаланыла торган объектларның һәм урыннарның сакланышын тәэмин итү, шулай ук гавами чараларда катнашмаган затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга юл куймау максатыннан, 2004 елның 19 июнендәге 54-ФЗ номерлы «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турында» Федераль закон,2012 елның 25 декабрендәге 91-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыруга хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә карар бирә:

1. Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 13 мартындагы 56 номерлы «Халык алдында чаралар үткәрү урынында территорияне (бинаны) иң чик тутыру нормалары турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"тротуарларда, административ бина яны мәйданнарында (мәгариф, медицина, физкультура-сәламәтләндерү, спорт оешмалары, социаль хезмәт күрсәтү, мәдәният, балалар һәм яшьләрнең ял итү оешмалары, мәдәни корылмаларга якын территорияләрдән тыш) һәм сәүдә үзәкләрендә, мәдәни-күңел ачу учреждениеләрендә һәм базар яны территорияләрендә- 3 кв.метрга бер кешедән артык түгел."

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А. Х. Шәмсетдинов